ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 2 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 93 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 өлешендә «Җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Муниципаль районнарның, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацта «Гаражлардан» сүзен «Җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган һәм гаражлардан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктта «җирле үзидарә органнарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе                                                                                    Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 16 ноябрь
№ 113-ТРЗ